КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 гыйнвар г.Казань № 51

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибе турында» 2023 ел, 27 апрель, 532 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибе турында» 2023 ел, 27 апрель, 532 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешма эшчәнлегенең төп төрләре әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә Икътисадый эшчәнлек төрләре исемлегендә каралган икътисадый эшчәнлек төрләренең берсенә туры килмәү. Әгәр оешма икътисадый эшчәнлегенең төп төре Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы нигезендә 26.20.4, 26.30.16, 46.51.2, 47.91.2, 58.11, 58.13, 58.14, 58.19, 58.21, 58.29, 59.14, 60.10, 60.20, 63.91, 71.20.9, 73.11, 73.12, 73.20.1, 74.90.9, 85.30, 85.41, 85.42, 95.11 кодлары туры килә торган төр булса, оешманы стартаплар реестрына кертү оешма тарафыннан бары 62 нче һәм (яки) 63 нче классларда каралган, Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы кодларына туры килә торган эшчәнлекнең өстәмә төрләрен гамәлгә ашырганда гына мөмкин була;»;

15 пунктта:

беренче абзацта «кушымта» сүзләрен «1 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

«г» пунктчасында «62 нче «Компьютер программа тәэминатын эшләү, бу өлкәдә консультация хезмәтләре һәм башка шуңа бәйле хезмәт күрсәтүләр» һәм (яки) 63 нче «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә эшчәнлек» классларында каралган» сүзләрен төшереп калдырырга;

17 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оешма эшчәнлегенең төп төрләрен Икътисадый эшчәнлек төрләре исемлегенә туры килми торган төрләргә әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә үзгәртү;»;

әлеге Тәртипкә кушымтада:

нумерация башисемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибенә 1 нче кушымта»;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә стартаплар реестрын булдыру һәм алып бару тәртибенә 2 нче кушымта

Икътисадый эшчәнлек төрләре
исемлеге

| Икътисадый эшчәнлек төренең коды/өстәмә классы/ классы/төркеме/ өстәмә төркеме* | Икътисадый эшчәнлек төренең исеме* |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 26.20.4 | Мәгълүматны саклау чараларын, шулай ук мәгълүматны саклау чараларын кулланып сакланган мәгълүмат һәм телекоммуникация системаларын җитештерү |
| 26.30.16 | Элемтә чаралары җиһазларын, кичектергесез эзләү чараларын үткәргәндә билгеләнгән гамәлләр башкаруны тәэмин итә торган программа тәэминатын җитештерү |
| 46.51.2 | Программа тәэминаты белән күпләп сату |
| 47.91.2 | Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәре ярдәмендә турыдан-туры гамәлгә ашырыла торган ваклап сату |
| 58.11 | Китаплар бастырып чыгару |
| 58.13 | Газеталар бастырып чыгару |
| 58.14 | Журналлар һәм вакытлы басмалар бастырып чыгару |
| 58.19 | Нәшрият эшчәнлегенең башка төрләре |
| 58.21 | Компьютер уеннарын эшләп чыгару |
| 58.29 | Башка программа продуктларын эшләп чыгару |
| 59.14 | Кинофильмнар күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек |
| 60.10 | Радиотапшыру өлкәсендә эшчәнлек |
| 60.20 | Телевизион тапшырулар өлкәсендә эшчәнлек |
| 62 | Компьютер программа тәэминатын эшләү, бу өлкәдә консультация хезмәтләре һәм башка шуңа бәйле хезмәт күрсәтүләр |
| 63.1 | Мәгълүматларны эшкәртү эшчәнлеге, мәгълүматны урнаштыру хезмәтләре күрсәтү, Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә порталлар эшчәнлеге |
| 63.91 | Мәгълүмат агентлыклары эшчәнлеге |
| 71.20.9 | Техник контрольдә тоту, сынаулар һәм анализ буенча башка эшчәнлек |
| 72.11 | Биотехнология өлкәсендә фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр |
| 72.19 | Башка табигый һәм техник фәннәр өлкәсендәге фәнни |

| 1 | 2 |
|---|---|
| | тикшеренүләр һәм эшләнмәләр |
| 73.11 | Реклама агентлыклары эшчәнлеге |
| 73.12 | Массакүләм мәгълүмат чараларында күрсәтү |
| 73.20.1. | Базар конъюнктурасын тикшерү |
| 74.90.9 | Мәгълүматны саклау өлкәсендә эшчәнлек |
| 85.30 | Һөнәри укыту |
| 85.41 | Балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү |
| 85.42 | Һөнәри өстәмә белем бирү |
| 95.11 | Компьютерларны һәм периферияле компьютер җиһазларын ремонтлау |

*Икътисадый эшчәнлек төрләренең исемнәре һәм кодлары Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы нигезендә билгеләнә.

---